


Республика матбугат vзәгендә «Кибермошенничество. Чынбарлык һәм профилактика» темасы буенча спикерлар дистанцион мошенникларга каршы тору турында фикер алыштылар, дип хәбәр итә РМ дәvләт хакимияте органнары сайты.
Агымдагы елнын беренче кварталында гына да Мордовия халкы мошенникларга 80 миллион сумнан артык акча кvчергән. Элеккечә, жинаять кылунын ин кин таралган ысулы - ялган банк яки хокук саклау органнары хезмәткәрләренә шалтырату. Икенче урында - интернет челтәрендә торле товарлар сату һәм сатып алу. Туганнары булып кvренгән мошенникларга акча кvчерvчеләр дә шактый.      Мондый фактларны булдырмау буенча кин таралган алдау схемалары һәм полициянен профилактик эше турында матбугат конференциясендә Россия эчке эшләр министрлыгынын Саранск шәһәре буенча жинаятьчеләрне эзләv бvлегенен гомуми жинаятьчелекне ачу бvлеге начальнигы Егор Петров сойләде.
Полиция хезмәткәрләре гражданнарга яшәv һәм эшләv урыннарында килеп, истәлекләр тараталар, подъездлардагы стендларга мәгълvмат листовкалары ябыштыралар, алдау турында аудиороликлар жәмәгать транспортында һәм сәvдә нокталарында трансляцияләнә. Шуна да карамастан, республика халкы мошенникларга ышануын дәвам итә, шунын белән акчаларын югалта», - дип билгеләп vтте Егор Петров. Ул шулай ук мошенникларнын диалогны ничек тозергә һәм гражданнардан акча алырга икәнен яхшы белvләрен ассызыклады һәм региональ матбугат вәкилләреннән бу моһим теманы кинрәк яктыртуларын сорады.
Матбугат конференциясендә кибер куркынычсызлыкнын топ кагыйдәләре турында да сvз барды - онлайн-мошенниклыкларны профилактикалау, легаль булмаган финанс онлайн-оешмаларынын нинди билгеләре һәм финанс оешмасын ничек тикшерергә кирәклеге турында.
«Банк хезмәткәрләре операцияне раслау очен сезнен белән элемтәгә керә алалар, ләкин тvләv картасы мәгълvматларын сорамыйлар. Бу мәгълvмат счетка керv очен мошенникларга гына кирәк булырга момкин. Аларнын хәйләләренә эләкмәс очен, башта анын банк хезмәткәре булу-булмавын тикшерергә кирәк. Анын исемен сорагыз, бvлекнен исемен ачык-лагыз һәм сонрак шалтыратыгыз дип әйтегез. Трубканы куегыз. Банкнын рәсми номерына шалтыратыгыз һәм сезгә шалтыраткан хезмәткәр белән элемтәгә керvне сорагыз. Бернинди очракта да кире шалтыратмагыз», - дип анлатты Россия Банкынын Волга-Вятка дәvләт университетынын Мордовия Республикасы буенча Милли банкы бvлекчәсенен иминлек бvлеге начальнигы Александр Петров.
Мордовия дәvләт университетынын психология кафедрасы доценты, психология фәннәре кандидаты Ирина Тараскина билгеләп vткәнчә, мошенниклар психологияне һәм кеше кочсезлекләрен, хисләр, борчылулар һәм куркулар белән уйный беләләр. Ул манипуляция ысуллары турында сойләде һәм аларга каршы тору буенча кинәшләр бирде.
Матбугат конференциясе ахырында спикерлар тагын бер тапкыр һәр граждан vзенен танышларына, бигрәк тә олкән яшьтәгеләргә, мошенник-лар корбаны булмас очен ничек эш итәргә кирәклеген житкерергә тиеш икәнлеген искә тошерделәр. Алар шулай ук Мордовиядә Стопмошенник13 телеграм-каналы эшләвен дә остәделәр, анда эчке эшләр

министрлыгы һәм Мордовия Республикасы НБ бvлеге реаль хәлләрне алып баралар һәм кешеләргә мошенникларга финанс кvчермәvдән ничек качарга кирәклеген сойлиләр.